УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Федосеевская, 36, г. Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

Федосеев ур., 36, Казан шәһәре, 420111

Телефон, факс (843) 221-77-85, сайт: www.gtn.tatarstan.ru, эл.почта: gostehnadzorrt@mail.ru

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

« 17 »　06　2021 ел.　　　　　　　　　　　　　№ 01-05/152-пр

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2021 елның 11 февралендәге 01-05/53-пр номерлы боерыгы белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатларында,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2021 елның 11 февралендәге 01-05/53-пр номерлы боерыгы белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Теркәү, автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу һәм махсус эш секторына әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталында Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе сайтында, «Документлар» бүлегенең «Административ регламентлар» бүлекчәсендә урнаштырырга.

Җитәкче вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы　　　　　　　　　　　　　　　　　　　М.Ә. Халиков

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2021 елның 11 февралендәге 01-05/53-пр номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 17.06.2021 №01-05/152-пр боерыгы редакциясендә)

# Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Регламент үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт теркәвенә алу, дәүләт хезмәте күрсәтү, Регламент) стандартын һәм тәртибен билгели.

Күләме 50 куб.сантиметрдан артыграк булган эчтән янучан двигательле яки максималь егәрлеге 4 киловаттан артыграк булган электр двигательле, үзйөрешле машина һәм башка төр техника (үзйөрешле машина һәм башка төр техниканың электрон паспортлары) паспорты рәсмиләштерелә торган тракторлар, үзйөрешле юлтөзелеш машиналары, коммуналь, авыл хуҗалыгы машиналары, юлсыз урыннардан йөри торган автомототранспорт чаралары һәм җир өстеннән йөри торган башка төрле рельссыз механик транспорт чаралары (двигателенең (двигательләренең) егәрлеге 4 киловаттан артык булган яисә максималь конструктив тизлеге сәгатенә 50 километрдан артык булган, кешеләрне, йөкләрне яки аларда урнаштырылган җиһазларны ташу өчен билгеләнгән, тәгәрмәчтә йөри торган «L», «M», «N» категориясендәге җир өсте үзйөрешле җайланмалардан, шулай ук аларның тагылмаларыннан (ярымтагылмаларыннан) һәм Россия Федерациясе Хәрби Көчләре, башка гаскәрләр, хәрби формированиеләр һәм органнар транспорт чараларыннан, үзйөрешле машиналарыннан, хәрби, махсус һәм башка төр техникадан, хәрби сынау (тәҗрибә) үрнәкләреннән, хәрби һәм махсус техникадан, шул исәптән чит ил дәүләтләре белән хәрби-техник хезмәттәшлек турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә хәрби билгеләнештәге продукциягә карый торган техникадан тыш), шулай ук үзйөрешле машина һәм башка төр техника паспорты (үзйөрешле машина һәм башка төр техниканың электрон паспортлары) рәсмиләштерелә торган үзйөрешле машина тагылмалары (ярымтагылмалары) (алга таба – техника) дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып түбәндәгеләр тора:

а) физик зат яисә шәхси эшкуар яки юридик зат –техника хуҗасы, түбәндәге булып торганда:

техника милекчесе (16 яше тулмаган яисә эшкә яраксыз дип танылган заттан тыш);

хуҗалык алып бару хокукында, оператив идарә хокукында яисә лизинг килешүе нигезендә техникага ия булган зат;

техника милекчесе булган, 16 яшенә җитмәгән затның ата-анасының берсе, уллыкка алучы заты яки опекуны (попечителе);

техника хуҗасы булган, эшкә сәләтсез гражданинның опекуны;

б) физик зат яки шәхси эшкуар яки юридик зат – сынау (тәҗрибә үткәрү) үрнәге булып торган, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап автомобильдә хәрәкәт итүгә бәйле, сынау техникасын әзерләүче (җитештерүче) зат тарафыннан расланган сынау техникасының сынаулар программасында күрсәтелгән сынауларны уздыру өчен билгеләнгән техниканы (алга таба – сынау техникасы) әзерләүче (җитештерүче) зат.

Техниканы дәүләт теркәвенә алу техника хуҗасының мөрәҗәгать итү урыны буенча, техниканың хуҗасы булган физик затның, шәхси эшкуарның кайда теркәлүенә яки юридик затның кайда урнашкан булуына бәйсез рәвештә гамәлгә ашырыла.

1.3. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә, Идарәнең территориаль бүлекләрендә теркәлми:

запас частьләрдән һәм агрегатлардан индивидуаль җыелган транспорт чаралары һәм техника;

Евразия икътисадый берлегенең таможня территориясенә 6 айдан да артмаган вакытка вакытлыча кертелгән яисә сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик зат яисә шәхси эшкуар саткан товар булып торучы техника;

Евразия икътисадый берлегенең таможня территориясенә 6 айдан артмаган срокка вакытлыча кертелгән, тулаем алганда яки кузов, рам яки шасси рәвешендә төп компонентлар рәвешендә башка техниканы ясау өчен кулланыла торган, ахыргы җитештерүчеләргә илтелә яки Россия Федерациясеннән чыгарыла торган техника, яисә сәүдә эшчәнлеген башкара торган юридик зат яки шәхси эшкуар тарафыннан сатыла торган техника булып торган техника;

сынау (тәҗрибә уздыру) үрнәге булган, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итүгә бәйле булмаган сынауларны уздыру өчен билгеләнгән техника.

1.4. Дәүләт хезмәте Идарә, Идарәнең территориаль бүлекләре (алга таба – Идарә бүлеге, баш дәүләт инженер-инспекторы, вазыйфаи зат) тарафыннан күрсәтелә.

1.4.1. Идарә урнашкан урын: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Федосеев урамы, 36 йорт.

Идарәнең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, җомга: 8.00 сәгатьтән 15.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Җәмәгать транспортында «Батурин» тукталышына кадәр килергә кирәк:

- 22, 28, 89 номерлы автобуслар.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, Идарә һәм Идарә бүлекләренең эш сәгатьләрендә, көн саен.

1.4.2. Идарә телефоннары: 8 (843) 221-77-85, 221-77-89.

Факс: 8 (843) 221-77-85.

1.4.3. Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://gtn.tatarstan.ru.

1.4.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә Идарә бүлекләренең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Идарәнең рәсми сайтында (http://gtn.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (https://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал);

3) Идарәгә һәм Идарә бүлекләренә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

4) Идарәгә һәм Идарә бүлекләренә язмача (шул исәптән электрон документ формасында да) мөрәҗәгать иткәндә;

5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәккә (алга таба – күпфункцияле үзәк) һәм күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарына мөрәҗәгать иткәндә.

Идарәнең Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» челтәрендә Идарәнең рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

1.4.5. Идарәнең урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Идарәнең электрон почтасы адресы турында мәгълүмат Идарәнең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Республика порталында урнаштырыла.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Идарәнең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.6. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

машинаны теркәү – теркәү турында таныклык һәм дәүләт теркәү билгесе биреп, машинаны яки тагылманы дәүләт исәбенә (техниканы дәүләт теркәвенә алганда Идарә бүлекләре файдалана торган теркәү журналында, төбәк мәгълүмат системасында (алга таба – исәпкә алу системасы)) кую, бу вакытта машина паспортына аның хуҗасы яки хуҗасын үзгәртү турындагы белешмәләр кертелә;

машинаны карау – машинаның, аның агрегатлары номерларын чагыштыру (номерларның машинаның паспортында күрсәтелгән мәгълүматларга туры килү-кил-

мәвен тикшерү);

күпфункцияле үзәк – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле гариза белән яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль) $15^1$ статьясында күрсәтелгән гариза белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң гамәлгә ашырыла торган, ә дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органнар белән үзара хезмәттәшлек итү норматив хокукый актлар һәм үзара багланышлар турындагы килешү нигезендә мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка гына күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырыла торган принцип;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы яки шәһәр округы шәһәр (авыл) җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

Автоматлаштырылган мәгълүмат системасы – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы;

Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы (алга таба – ИАБС) – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 1 пункты). Гаризаларның формалары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 21 сентябрендәге 1507 номерлы карары белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләренә 1, 2 номерлы кушымтада каралган һәм Регламентның 1 нче, 2 нче кушымталарында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен теркәү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 21 сентябрендәге 1507 номерлы карары белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләре (алга таба – Машиналарны теркәү кагыйдәләре) |
| 2.2.Башкарма хакимият органының исеме | Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе һәм Идарә бүлекләре | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1064 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе турындагы нигезләмә |
| 2.3.Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:<br>техниканы дәүләт теркәвенә алу турында таныклык, дәүләт теркәү билгесе, теркәүне гамәлгә ашыру, теркәү белешмәләрен үзгәртү турында тамгалап, техника паспорты техниканың электрон паспортыннан | Машиналарны теркәү кагыйдәләре |

| | | |
|---|---|---|
| | өземтә, техника паспорты дубликаты яисә югалганы, файдалану өчен яраксызга чыкканы яки билгеләнгән үрнәккә туры килми торганы өчен алмашка техниканың электрон паспортыннан өземтә бирү (техниканы дәүләт теркәвенә алу, теркәү белешмәләренә үзгәрешләр кертү очрагында);<br>«Транзит» дәүләт теркәү билгесе бирү (техникага карата милекчелек хокукы чит ил физик затына яки чит ил юридик затына күчүгә бәйле рәвештә читләштерү өчен, Россия Федерациясе территориясе чикләренә чыгарылачак техниканы дәүләт теркәвеннән алган очракта, Россия Федерациясеннән чыгаруга бәйле рәвештә техниканы, шулай ук тулаем алганда яисә кузов, рам яки шасси рәвешендәге төп компонентлар рәвешендә башка техниканы ясау өчен куллана торган, ахыргы кулланучыларга җиткерелә яисә Россия Федерациясеннән читкә җибәрелә торган техниканы дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкны рәсмиләштергәндә);<br>техниканы дәүләт теркәвеннән алу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү. | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору | Гаризаларны (техниканы дәүләт теркәвенә алу, техниканың теркәү мәгълүматларына үзгәрешләр кертү турында яки техниканы дәүләт исәбеннән төшерү турында) карау өчен – Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң 5 эш көне.<br>Техниканы карау өчен – техниканы дәүләт теркә- | Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 65 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | венә алудан баш тарту өчен нигезләр булмавы турында карар кабул ителгән көннән башлап 10 эш көне.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны бирү үзйөрешле техниканы карап чыкканнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору:<br>Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 64 пунктында күрсәтелгән сорауга җавап алу, шулай ук Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 19 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча тикшерү үткәрү вакытына техниканы дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтү 30 календарь көненнән артмаган вакытка туктатыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны электрон документ формасында җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла. | Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 64 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче | Техниканы дәүләт теркәвенә алу өчен түбәндәге документлар тапшырыла:<br>әлеге Регламентнң 1 нче кушымтасына ярашлы форма буенча (юридик затлар өчен), 2 нче кушымтасына ярашлы форма буенча (физик затлар өчен);<br>техника хуҗасының яисә аның вәкиленең шәхесен таныклаучы документ (гариза биргәндә күрсәтелә), Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә гариза бирү очракларыннан тыш; | Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 6, 23, 24, 29, 48, 50, 51, 57 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | техника хуҗасы вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документ, әгәр документлар вәкил тарафыннан тапшырылса;<br>техникага яки төп компонентларга ия булу һәм алардан файдалану хокукын яисә башка законлы нигезне раслаучы документ;<br>утильләштерү җыемын түләү турында тамгалап яки Россия Федерациясе законнары нигезендә утильләштерү җыемын түләмәү нигезе турында тамгалап, машина паспорты яки үзйөрешле машина һәм башка төр техниканың электрон паспортлары системасында «гамәлдә» статусы белән машинаның электрон паспортыннан (алга таба – техниканың электрон паспорты) 2014 елның 15 августындагы Транспорт чарасы паспортының (транспорт чарасы шассие паспортының) һәм үзйөрешле машина һәм башка төр техника паспортының бердәм формаларын алып бару һәм электрон паспортлар системасын оештыру турындагы килешү нигезендә рәсмиләштерелгән, утильләштерү җыемын түләү турында тамгалап яки, Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 16 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, Россия Федерациясе законнары нигезендә утильләштерү җыемын түләмәү нигезе турында тамгалап өземтә;<br>Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, техниканы вакытлыча кертелгән буларак тәңгәлләштерүче документ.<br>Теркәү исәбеннән төшерү өчен әлеге пунктның икенче-дүртенче һәм алтынчы абзацларында күрсәтелгән документлар, шулай ук техниканы дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| | теркәвенә алу турында таныклык һәм дәүләт теркәү билгесе (булган очракта) тапшырыла.<br>Читләштерүгә бәйле рәвештә техниканы дәүләт исәбеннән төшергәндә, техниканы читләштерүгә юнәлдерелгән алыш-бирешне төзү турындагы документлар, техника паспортлары, дәүләт теркәү билгесе һәм техниканы дәүләт теркәвенә алу турында таныклык тапшырыла, техникага яңа хуҗасы буенча дәүләт теркәвенә алуның уздырылмаган булу шарты белән.<br>Судлар, тикшерү органнары, таможня органнары тарафыннан теркәлү эшләрен башкаруга тыюлар яисә чикләүләр кертелгән булган техниканы исәптән төшерү өчен күрсәтелгән тыюларның яисә чикләүләрнең яисә әлеге техниканы читләштерү һәм аны милек итеп башка затларга тапшыру турында яисә дәүләт мөлкәтенә юнәлдерү турында судларның карарлары булмавы турында таныклый торган документлар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнарында башка тәртибе каралмаган булса.<br>Сынау (тәҗрибә уздыру) үрнәге булган, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итүгә бәйле сынаулар уздыру өчен билгеләнгән техниканы дәүләт теркәвенә алу вакытында әлеге пунктның икенче-дүртенче абзацларында күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә сынау техникасын әзерләүче (җитештерүче) зат тарафыннан расланган сынау техникасын сынаулар программасы тапшырыла.<br>Техниканың теркәү мәгълүматларына лизингка алучы турында үзгәрешләр кертү өчен лизинг килешүе буенча хокукларны һәм бурычларны башка затка бирү | |

| | | |
|---|---|---|
| | турында килешү һәм алу-тапшыру актв тапшырыла, әгәр лизинг килешүендә башкача каралмаган булса.<br>Лизингка алучы зат өчен чикләнгән срокка теркәлгән техниканың хуҗасы алмашынуга бәйле рәвештә теркәү белешмәләренә үзгәрешләр кертелгән очракта, лизинг килешүен өзү турында документ яки техниканы читләштерү турында раслый торган документ тапшырыла.<br>Техниканы дәүләт теркәвенә алу өчен тапшырыла торган, чит телдә төзелгән документлар рус теленә тәрҗемә ителгән һәм нотариусның яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә нотариаль эшләр башкаруга хокукы булган башка вазыйфаи затның тәрҗемәнең дөрес булуы турында таныклый торган язуларына ия булырга тиеш<br>Техниканы дәүләт теркәвенә алу өчен, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүләрендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясеннән читтә, башка дәүләтләрнең рәсми органнары тарафыннан бирелгән документлар кабул ителә, алар консуллык вазыйфаи затлары тарафыннан легальләштерелгән булырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза кәгазен мөрәҗәгать итүче Идарә бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон формасы Идарәнең рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала: | |

| | | |
|---|---|---|
| | 1) кәгазь чыганакларда Идарәгә шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан) яки почта аша юллап яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (тамгаланган) электрон документлар рәвешендә рәсми электрон почтага;<br>2) күпфункцияле үзәк аша кәгазьдә яки 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә.<br>Гаризаны тапшырган вакытта мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктән гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган теркәү номеры һәм электрон гаризаны тапшыру датасы белән язу бирелә.<br>3) Республика порталы аша электрон формада.<br>Гаризаны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерүне ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.<br>Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик багланышларын тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация- | |

| | | |
|---|---|---|
| | ләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын да расларга кирәк.<br>Гариза Республика порталы аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче документларның электрон рәвешләрен яисә 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә мондый документларны төзү һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган электрон формадагы документларны тапшыра.<br>Гаризага мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган (гариза мөрәҗәгать итүче вәкиле тарафыннан тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклый торган) документның күчермәсе мондый документның электрон рәвешендә теркәлә.<br>Гариза Республика порталындагы шәхси кабинет аша җибәрелгән очракта әлеге документны тапшыру таләп ителми, әгәр гариза көчәйтелгән квалификация-ле электрон имза белән имзаланган булса.<br>Гариза мөрәҗәгать итүченең ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкиле аша тапшырылган очракта, гаризага шулай ук мондый документның электрон рәвешендәге ышаныч кәгазе дә теркәлә. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган белешмәләр: | Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 6 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | дәүләт пошлинасын түләү факты турында (Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсендә);<br>техниканың электрон паспортын рәсмиләштерү турында (вәкаләтле органда);<br>транспорт чарасы хуҗасының граждани җаваплылыгын иминиятләштерү буенча иминият полисы (вәкаләтле органда);<br>мәҗбүри сертификацияләү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракта, ярашлылык сертификаты яки ярашлылык декларацияләре (вәкаләтле органда);<br>Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә);<br>Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле документларны мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә дә тапшырырга хокуклы.<br>Гариза Республика порталы аша тапшырылган очракта мөрәҗәгать итүче Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне), мондый документларны төзү һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән таныкланган электрон документлар формасында яки күпфункцияле үзәккә кәгазь чыганакта тапшыра ала.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә | |

| | | |
|---|---|---|
| | кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән Документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;<br>гаризада билгеләнгән тәртиптә расланмаган хаталар һәм төзәтүләр булуы;<br>гариза һәм 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру (гаризаны электрон формада тапшырган очракта).<br>Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Республика порталында, Бердәм порталда һәм Идарә сайтында урнаштырылган, хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту рөхсәт ителми | «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә карата таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә карата таләпләрнең (алга таба – Таләпләр) 7 пункты |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре:<br>техниканы дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар, исәптән төшерелгән техника паспортлары | Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 19 пункты, 64 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| исемлеге | югалган очракта яки техниканы дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкларның, техника, техниканың төп компонентлары паспортларының дөреслегендә шик барлыкка килгәндә һәм аларның номерлары тапшырылган документларга туры килмәгән очракта;<br>тапшырылган документларны, дәүләт теркәү билгеләрен ялганлап ясау, җитештерү оешмалар тарафыннан техникага ясалган маркировканы үзгәртү яки юкка чыгару билгеләре ачыкланган очракта, шулай ук техниканың яки техниканың төп компонентларының (двигатель, төп хәрәкәт мосты (мостлары), рам, тизлек күчерү коробкасы) эзләтелүе турында белешмәләр булганда яисә тапшырылган документлар урланганнар исәбендә торган очракта.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>Машиналарны теркәү кагыйдәләре нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле булмаган аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гариза белән мөрәҗәгать итү;<br>Машиналарны теркәү кагыйдәләре нигезендә мәҗбүри булырга тиешле документлар яки белешмәләр булмавы;<br>тапшырылган документларның норматив хокукый актларда яисә норматив-техник документларда билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;<br>гамәлдә булу вакыты чыккан документлар тапшырылуы;<br>тапшырылган (алынган) документларда (белешмәләрдә) каршылыклы яисә дөрес булмаган мәгълүмат булуы; | Машиналарны теркәү кагыйдәләренең 58 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | Россия Федерациясе законнары нигезендә салынган тыюлар һәм (яки) чикләүләр булуы;<br>бирелгән (алынган) документларның (белешмәләрнең) тикшерү вакытында алынган документларга (белешмәләргә) туры килмәве;<br>исәпкә алу системасында дәүләт исәбеннән алынмаган техниканы дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар булуы (техниканы дәүләт теркәвенә алу турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә);<br>Россия Федерациясе законнары нигезендә утильләштерү җыемын түләү турында техника паспортында тамга яисә утильләштерү җыемын түләмәү нигезе турында тамга булмавы;<br>электрон паспортта «гамәлдәге» статусына ия булган техниканың Россия Федерациясендә утильләштерү җыемын түләү турында яки утильләштерү җыемын түләмәү нигезе турында белешмәләр булмавы.<br>Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту рөхсәт ителми | Таләпләрнең 7 пункты |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | 1. Үзйөрешле техниканы яки тагылманы теркәү:<br>– дәүләт теркәү билгесен бирү – 1500 сум;<br>– теркәлү турында таныклык бирү – 500 сум;<br>– паспортка үзгәрешләр кертү – 350 сум.<br>Барлыгы: дәүләт пошлинасы 2350 сум. | Россия Федерациясе Салым кодексының 333.3 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | 2. Элек теркәлгән транспорт чараларын аларның тору урыны буенча вакытлыча теркәү:<br>– дәүләт пошлинасы – 350 сум.<br>3. Үзйөрешле машинаны яки тагылманы исәптән төшерү:<br>– дәүләт пошлинасы: 350 сум.<br>4. Транспорт чарасы паспортын, үзйөрешле машина һәм башка төр техника паспортларын, шул исәптән югалган яки яраксызга килгәне урынына алмаш итеп:<br>– паспорт бирү – 800 сум.<br>– теркәү турында таныклык бирү – 500 сум.<br>Барлыгы: дәүләт пошлинасы 1300 сум.<br>5. Югалган яки яраксызга килгәне урынына алмашка транспорт чарасын теркәү турында таныклык бирү:<br>– теркәү турында таныклык бирү – 500 сум.<br>– паспортка үзгәрешләр кертү – 350 сум.<br>Барлыгы: дәүләт пошлинасы 850 сум.<br>6. «Транзит» транспорт чаралары дәүләт теркәү билгеләрен бирү, шул исәптән югалган яки яраксызга чыкканнары урынына алмаш итеп, кәгазь нигезендә чыгым материалларыннан эшләнә торганнары – 200 сум. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| турында белешмәләр | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гаризаны һәм документларны тапшырган көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.<br>Гаризаны һәм теркәлә торган документларны күпфункцияле үзәккә тапшырган очракта, гариза килгән көнендә вазыйфаи күрсәтмә нигезендә гаризаны кабул итү һәм теркәүне гамәлгә ашыра торган | |

| | | |
|---|---|---|
| | күпфункцияле үзәк хезмәткәре (алга таба – КФҮ хезмәткәре) тарафыннан теркәлә.<br>Гаризаны һәм теркәлә торган документларны Идарә белән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Идарәгә тапшыру тәэмин ителә.<br>Күпфункцияле үзәк аша килгән гариза һәм теркәлә торган документлар Идарәгә алынган көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, һаваны кондиционерлау системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:<br>бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;<br>объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, бинага керү һәм объектка керү, | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;<br>күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;<br>инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның ноктालы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә озата йөри торган этне кертү;<br>хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрә-җәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.<br>2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга | |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Идарә, Идарә бүлекләре биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Идарәнең рәсми сайтында, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы; | |

| | | |
|---|---|---|
| файдалану турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (алга таба – комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, җирле үзидарәнең үтәү-боеру органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә дә) мөмкинлеге яки аннан файдалана алмау | Идарә, Идарә бүлекләре белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>Мөрәҗәгать итүченең Идарә, Идарә бүлекләре белгечләре белән бәйләнешкә кереп, хезмәттәшлек итү күләме:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда, турыдан-туры – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кирәкле барлык документлар белән гариза биргән вакытта мөрәҗәгать итүче бер тапкыр күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре белән үзара хезмәттәшлек итә;<br>күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтүнең электрон документ формасындагы нәтиҗәсен кәгазьдә алу зарурлыгы булган очракта, – бер тапкыр.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә бер тапкырдан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә үзара хезмәттәшлек итүнең вакыт озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://www.gtn.tatarstan.ru сайтыннан, Республика порталыннан http://www.uslugi.tatarstan.ru, күпфункцияле үзәк аша (хезмәт күрсәтү өчен гариза күпфункцияле үзәк аша тапшырылган очракта) алынырга мөмкин.<br>Идарәдә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән | |

| | | |
|---|---|---|
| | файдалану өчен кирәкле рәсми мөрәҗәгатьләрне, документларны, мәгълүматны тапшыру, шулай ук мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алу Идарәнең мондый хезмәтләрне күрсәтә торган теләсә кайсы структур бүлекчәсендә яки, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында күрсәтелгән килешү булган очракта, Татарстан Республикасы территориясендә чикләрендә мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, аның яшәү яки тору урынына (физик затлар өчен, шәхси эшкуарларны да кертеп) яки урнашкан урынына (юридик затлар өчен) бәйсез рәвештә, күпфункцияле үзәктә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында күрсәтелгәндә, күпфункцияле үзәк белгече, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарындагы белгеч консультацияли, документларны кабул итә һәм бирә (мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап).<br>Техник мөмкинлек булган очракта, кирәкле документларны электрон рәвештә тапшыру (күпфункцияле үзәкнең электрон санлы имзасы белән имзаланган документларның скан-рәвешләре) күпфункцияле үзәкнең мәгълүмат системасы аша башкарыла. Бу очракта кәгазь документлар күпфункцияле үзәк белән килешүдә күрсәтелгән ешлыкта Идарәгә җибәрелә.<br>Мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге юк. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр | Мөрәҗәгать итүче Идарәгә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә консультация бирелергә мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте электрон формада, шул исәптән Республика порталыннан файдаланып та, күрсәтелә.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:<br>1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;<br>2) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны да, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;<br>3) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;<br>4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;<br>5) дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгән кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган Республика порталы аша | 63-ФЗ номерлы Федераль закон,<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | Идарәнең, шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерә ала.<br>Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.<br>Республика порталы аша җибәрелгән гаризада бу хакта күрсәтелгән булса, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Республика порталы аша электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында бирелә.<br>Гаризаны электрон рәвештә формалаштырганда мөрәҗәгать итүчегә түбәндәге мөмкинлекләр тәэмин ителә:<br>хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм башка документларның күчермәләрен алу һәм саклап кую;<br>гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;<br>файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән электрон формага ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон формага элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;<br>ИАБС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, ИАБС системасында урнаштырылган һәм Республика порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан | |

| | | |
|---|---|---|
| | белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон форма кырларын тутыру;<br>элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;<br>мөрәҗәгать итүченең Республика порталында элегрәк бирелгән гаризаларны карый алу мөмкинлеге.<br>Гаризаны җибәргән вакытта, мөрәҗәгать итүченең шәхесе исәпкә алу язуын активлаштырганда билгеләнгән булу шарты белән, гади электрон имза кулланыла.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Республика порталы, күпфункцияле үзәкнең элемтә үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.<br>Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә буш булган теләсә нинди кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.<br>Республика порталы аша алдан язылу өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:<br>Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);<br>телефон номерын;<br>электрон почта адресын (ихтыярына карап);<br>кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.<br>Алдан язылганда мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга | |

| | | |
|---|---|---|
| | туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.<br>Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.<br>Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.<br>Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.<br>Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә дә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза төзү өлешендә;

гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү, тапшырылган документларны тикшерү;

ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуы (булмавы) турында карар кабул итү;

техниканы карау;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм бирү;

техник хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза төзү өлешендә.

Мөрәҗәгать итүче Идарәгә һәм/яки Идарә бүлекләренә шәхсән, почта аша, телефон буенча, Республика порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша һәм (яки) электрон почта буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итә.

Идарә һәм/яки Идарә бүлекләре белгече шәхсән, телефоннан, электрон почта һәм (яки) хат белән, Республика порталы аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның рәвеше һәм эчтәлеге буенча һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән аны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның формасы һәм эчтәлеге буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану алу өчен башка мәсьәләләрдә мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, зарурлык булганда гаризаны рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтү.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү, тапшырылган документларны тикшерү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән кәгазьдә яисә электрон формада Бердәм портал аша Идарә бүлегенә, әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар теркәп, гариза тапшыра.

3.3.2. Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

гариза белән документларны кабул ителәә;

документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында билгеләнгән нигезләр булган очракта, мөрәҗәгать итүчегә, баш тарту сәбәпләрен язмача нигезләп, документлар кайтарып бирелә.

Мөрәҗәгать итүче Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына автомат рәвештә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, баш тарту турындагы нигезле сәбәпләр белән, документның электрон рәвеше җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны кабул итүдән язмача баш тарту.

3.3.3. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаган очракта, баш дәүләт инженер-инспекторы гаризаны һәм документларны терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән (гариза почта аша алынган) көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә, түбәндәге белешмәләрне бирү турында:

дәүләт пошлинасын түләү факты турында – Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсендә;

техниканың электрон паспортын рәсмиләштерү турында – вәкаләтле органда;

транспорт чарасы хуҗасының граждани җаваплылыгын иминиятләштерү буенча иминият полисы – вәкаләтле органда;

мәҗбүри сертификацияләү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракта, ярашлылык сертификаты яки ярашлылык декларацияләре – вәкаләтле органда;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан – Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә;

Әлеге Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документларны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгать.

3.4.1. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр, законнарда билгеләнгән чорда, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында белдерү (алга таба – баш тарту турында белдерү) җибәрә.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуы (булмавы) турында карар кабул итү.

Әлеге Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән белешмәләр алынганнан соң, Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан техниканы дәүләт

теркәвенә алудан баш тарту өчен нигезләр булуы (булмавы) турында карар кабул ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, баш дәүләт инженер-инспекторы документларны карау көнендә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү бирү (җибәрү) турында карар кабул итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү мөрәҗәгать итүчегә язмача, шул исәптән Бердәм порталдагы шәхси кабинетына да, җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына автомат рәвештә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, процедура нәтиҗәсе булган документның электрон рәвеше җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә бүлегенә җибәрелгән, рәсми мөрәҗәгатькә җавап бирү нәтиҗәсе булган документлар, белешмәләр, баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуы (булмавы) турында карар кабул итү, дәүләт хезмәтеннән баш тарту турында белдерү бирү (җибәрү).

3.6. Техниканы карау.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан техниканы карау өчен датасы, урыны һәм вакыты мөрәҗәгать итүче белән килештерелә (гамәлдән чыгарулына (утильләштерелүенә) бәйле рәвештә техниканы теркәү исәбеннән төшерү, сынау (тәҗрибә уздыру) үрнәге булып торган, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буенча хәрәкәт итүгә бәйле сынауларны уздыру өчен билгеләнгән техниканы дәүләт теркәвенә алу очракларыннан тыш).

Техниканы караганда:

- ул идентификацияләнә;
- техниканың завод, идентификация номерын яки техниканың төп компоненты номерын үзгәртү, яшерү, юкка чыгару билгеләренең булмавы тикшерелә;
- конструкциясенең тапшырылган документларга туры килү-килмәве тикшерелә, ә кирәк булган очракларда, техника конструкциясенә кертелгән үзгәрешләрнең конструкциясенә үзгәрешләр кертелгән техниканың куркынычсызлык таләпләренә туры килүе турындагы документларга туры килү-килмәве тикшерелә.

Техниканы карап бетергәннән соң техниканы дәүләт теркәвенә алу турындагы гаризага аның нәтиҗәләре турында билге кертелә.

Процедура техниканы дәүләт теркәвенә алудан баш тарту өчен нигезләр булмавы турында карар кабул ителгән көннән соң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: техниканы карау.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору.

Тапшырылган документларны, дәүләт теркәү билгеләрен ялганлап ясау, техникага аны җитештергән оешмалар тарафыннан ясалган маркировканы үзгәртү яки юкка чыгару билгеләре ачыкланган очракта, шулай ук техниканың яки техниканың төп компонентларының (двигатель, төп хәрәкәт мосты (мостлары), рам, тизлек күчерү

коробкасы) эзләтелүе яисә тапшырылган документларның урланганнар исәбендә булуы турында белешмәләр булганда, Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аларны тикшерә, техниканы алдан дәүләт теркәвенә алу урыны буенча рәсми мөрәҗәгатьләр юллый, аларның үтәлеше аларны алганнан соң 3 эш көне эчендә мәҗбүри гамәлгә ашырылырга тиеш.

Рәсми мөрәҗәгатьләр буенча җаваплар алу вакытына техниканы дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, ләкин 30 календарь көненнән дә артмаган чорга.

Техниканы дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүне туктатып тору турындагы карарны техниканы дәүләт теркәвенә алу турында яисә техниканың теркәү документларына үзгәрешләр кертү турындагы гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча җибәреп яисә башка төрле ысул белән хәбәр ителә.

Техниканы дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтү техниканы дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору сәбәпләрен юкка чыгаруны раслаучы документлар алынган көннән яңартып җибәрелә.

Процедура техниканы карау көнендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү срогын туктатып тору, мөрәҗәгать итүчегә техниканы дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында хәбәр итү, дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү.

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм бирү.

Техниканы карау нәтиҗәләре буенча җитештерүче оешмалар тарафыннан техникага ясалган маркировканы үзгәртү яки юк итү билгеләре булмаса, шулай ук техникага карау үткәрелмәгән очракта да, баш дәүләт инженер-инспекторы:

3.8.1. Техниканы дәүләт теркәвенә алу турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә:

техникага дәүләт теркәү номеры беркетә һәм ГОСТ Р 50577-2018 «Россия Федерациясе Илкүләм стандарты. Транспорт чараларының дәүләт теркәү билгеләре. Төрләре һәм төп үлчәмнәре. Техник таләпләр» нигезендә дәүләт теркәү билгесен тапшыра;

техникага уздырылган дәүләт теркәве турында техника паспортына тамгалар кертә (техниканың электрон паспортлары булмаган очракта);

техниканы дәүләт теркәвенә алганда техника паспортында милекчесе, аның адресы, сату (тапшыру) датасы турында язулар булмаган очракта, техника хуҗасы тарафыннан тапшырылган, техникага милек хокукынраслый торган документлар нигезендә әлеге юлларны тутыра;

техниканы дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча) рәсмиләштерә.

3.8.2. Теркәү мәгълүматларына үзгәрешләр кертү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә:

техниканың теркәү мәгълүматларына үзгәрешләр кертә;

техника паспортына (техниканың электрон паспортлары булмаганда) теркәү мәгълүматларына үзгәрешләр кертү турында билге кертә;

югалганнары яки файдалану өчен яраксызланганнары өчен алмаш итеп теркәү

документларының, техника паспортларының яки техника паспортына яки техниканың электрон паспортына язу теркәп, теркәү турындагы таныклыкларның дубликатларын рәсмиләштерә.

3.8.3. Техниканы исәптән төшерү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә:

техниканы дәүләт исәбеннән төшерә;

техника паспортына (техниканың электрон паспортлары булмаганда) техниканы исәптән төшерү турында билге кертә;

теркәү турындагы таныклыкка машинаны исәптән төшерү турында тамга куя;

техникага карата милекчелек хокукы чит ил физик затына яки чит ил юридик затына күчүгә бәйле рәвештә читләштерү өчен, Россия Федерациясе территориясе чикләренә чыгарылачак, дәүләт исәбеннән төшерелгән техникага, Россия Федерациясеннән чыгаруга бәйле рәвештә техниканы, шулай ук тулаем алганда яисә кузов, рам яки шасси рәвешендәге төп компонентлар рәвешендә башка техниканы ясау өчен кулланыла торган, ахыргы кулланучыларга җиткерелә яисә Россия Федерациясеннән читкә җибәрелә торган техникага дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкны рәсмиләштергәндә «Транзит» дәүләт теркәү билгесен рәсмиләштерә.

3.8.4. Дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкларда һәм техника паспортларындагы язулар басма җайланмалардан файдаланып башкарыла.

Техниканы дәүләт теркәвенә алу турында электрон документ рәвешендәге таныклык баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән таныклана.

Техниканы дәүләт теркәвенә алу турындагы гаризаны Бердәм порталдан файдаланып тапшырган очракта, техниканы дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, техниканы дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык, электрон документка өстәп, Идарә бүлегендә кәгазьдә дә бирелә.

Мөрәҗәгать итүче Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына автомат рәвештә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон рәвеше җибәрелә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар әлеге Регламентның 3.6 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү, бирү (җибәрү).

3.8.5. Техниканы дәүләт теркәвенә алу:

Россия Федерациясе гражданнарыныкы һәм шәхси эшкуарларныкы булганнарын – Идарә бүлеге тарафыннан исәпкә алу системасына аларның Татарстан Республикасы территориясендә яшәгән урыннары адресларын кертеп гамәлгә ашырыла;

яшәү урыны буенча теркәлмәгән Россия Федерациясе гражданинының техникасын – Татарстан Республикасы территориясендә тору урыны адресын исәпкә алу системасына кертеп гамәлгә ашырыла;

юридик затларныкы булганнарын – юридик затлар урнашкан урыннар чикләрендә юридик затларның адресларын яисә аларның аерымланган бүлекчләре урнашкан урыннарның адресларын исәпкә алу системасына кертеп гамәлгә ашырыла;

Татарстан Республикасында урнашкан дипломатик вәкиллекләргә, консуллык учреждениеләренә, халыкара (дәүләтара) оешмаларга, халыкара (дәүләтара) оешмалар вәкиллекләренә, халыкара (дәүләтара) оешмалар каршындагы вәкиллекләргә, шулай ук аларның Россия Федерациясе Чит эшләр министрлыгы каршында аккредитацияләнгән хезмәткәрләренә караганнарын – тиешле оешмаларның һәм физик затларның урнашу урынының адресын исәпкә алу системасына кертеп, Идарә бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла;

Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча торган чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган, шулай ук вакытлыча сыенып урын алган, качак дип танылган затларга караганнарын – чит ил гражданинының яисә гражданлыгы булмаган затның тору урынына килүе турындагы белдерүнең өзеп алына торган өлешендә күрсәтелгән адресны исәпкә алу системасына кертеп гамәлгә ашырыла;

Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча яисә даими яшәүче чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга караганнарын – яшәүгә рөхсәт кәгазендә яисә вакытлыча яшәү өчен бирелгән рөхсәт кәгазендә күрсәтелгән, Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны адресын исәпкә алу системасына кертеп гамәлгә ашырыла;

чит ил юридик затларына караганнарын – чит ил юридик затларының структур бүлекчәләренең (вәкиллекләренең, бүлекчәләренең, филиалларының) Татарстан Республикасында урнашкан урын адресларын исәпкә алу системасына кертеп гамәлгә ашырыла.

3.9. техник хаталарны төзәтү.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән кәгазьдә яисә электрон формада Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән техник хаталарны (язу, басма хаталарны, грамматик яки арифметик ялгышларны) бетерү турында гариза тапшырыла.

Үзгәртеп рәсмиләштерү техник хатасы булган, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан бирелгән документ белән бергә теркәлгән гариза (киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Баш дәүләт инженер-инспекторы:

техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гаризаларны теркәү журналында терки;

машина яисә тагылма турында белешмәләрне автоматлаштырылган исәпкә алу системасына кертә;

техник хатасы булган документны үзгәртеп рәсмиләштерә.

Баш дәүләт инженер-инспекторы мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән үзгәртеп рәсмиләштерелгән документ турында хәбәр итә.

Мөрәҗәгать итүче Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына автомат рәвештә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон рәвеше җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, үзгәртеп рәсмиләштерелгән документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору Идарә җитәкчесе, Идарә бүлегендәге вазыйфаи затлар тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту Идарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Идарә бүлекләре турындагы нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (Регламенттагы) таләпләргә туры килү-килмәвенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә Идарә (бүлек) эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1' өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Идарә (Идарә бүлекләре) хезмәткәрләре, Идарә, Идарә бүлекләре, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Идарә бүлеге хезмәткәрләре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Идарәнең бүлек башлыгына бирелә.

Идарә бүлеге башлыгы карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Идарәгә тапшырыла.

Идарә башлыгы карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә тапшырыла.

Күпфункцияле үзәк карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручы затка (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка) бирелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый

актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи зат, дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, http://gtn.tatarstan.ru рәсми сайтыннан, Республика порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Республика порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә граждан хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән

басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.7. Әлеге Регламентның 5.6 пунктының 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча, Мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә һәм, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, электрон формада да, шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, Мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

## 6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) документлар белән гаризаны Идарәгә җибәрү;

4) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

6.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәкнең http://mfc16.tatarstan.ru/ сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы заты аша яки электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына документлар тапшыра.

6.3.2. Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

5.4. Идарәгә гариза җибәрү.

6.4.2. Күпфункцияле үзәк белгече гаризаны Идарәгә, Идарә бүлегенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарә белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Идарә белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, Идарә белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – Идарәгә юлланган гариза.

6.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

6.5.1. Күпфункцияле үзәк белгече, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен Идарәдән алган вакытта, аны билгеләнгән тәртиптә терки, гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Идарәдән документлар алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

6.5.2. Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыра

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

6.6. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.6.1. Халыкның мәшгульлек үзәгендә бирелгән бәяләмәдәге хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турындагы гаризаны мөрәҗәгать итүче шәхсән яки ышанычлы заты аша күпфункцияле үзәккә язмача тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.7. Идарәгә техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү.

6.6.2. Күпфункцияле үзәк белгече Идарә белән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны Идарәгә җибәрә.

Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

форма Үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләренә 1 нче кушымтада китерелгән

Кая______________________________________________________________

(үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торшышы һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органының тулы атамасы (алга таба – дәүләт техник күзәтчелек органы))

## Гариза

Кемнән______________________________________________________________,

(юридик затның яисә юридик затның аерымланган бүлекчәсенең тулы атамасы)

индекс: ______________, юридик затның урнашкан урыны чикләрендә юридик затның адресы яисә аның аерымланган бүлекчәсенең урнашкан урын адресы

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________

| Тел. | Төп дәүләт теркәү номеры | Салым түләүченең тәңгәллек номеры |
|---|---|---|
| | | |

сорыйм ______________________________________________

(үтенечнең нигезе һәм асылы бәян ителә, үзйөрешле машинаның һәм

______________________________________________________

һәм башка төр техниканың атамасы, маркасы, теркәү билгесе күрсәтелә)

Түбәндәге документларны тапшырам:

үзйөрешле машина һәм башка төр техника паспорты (алга таба – техника):

сериясе ____________________номеры ______________________________;

ОСАГО полисы номеры

сериясе ______________________________ ____________________

Техникага милек хокукын раслаучы документлар,

______________________________________________________________

Башка

_______________________________________________________________________________
документлар_________________________________________________________________

Дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр (түләү йөкләмәсе) түләү турында квитанция)

Документ N ________; дата «__» _____ 20__ ел; сумма: ________ сум.
Документ N ________; дата «__» _____ 20__ ел; сумма: ________ сум.
Документ N ________; дата «__» _____ 20__ ел; сумма: ________ сум.

Техника турында мәгълүматлар

Атамасы, маркасы
Завод номеры, идентификация номеры
(VIN яки PIN) Двигательнең завод номеры
Тизлек күчерү коробкасының номеры Төп хәрәкәт мостының номеры
Төсе _________ Җитештерү елы_________ Утлы маякчык_______

Рәсмиләштерүне үткәрү түбәндәгегә ышанып тапшырыла

Туу датасы
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))
Шәхесне раслаучы документ,

(шәхесне раслаучы документ исеме, серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
Телефон Электрон почта адресы (булган очракта)__________________

Җитәкче ___________________________ / ___________________________
(имза) (фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))

Мөһер урыны
булган очракта
«__» ____________ 20__ ел.
Минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза:
«__» ____________ 20__ ел. Имза ___________________________

Гаризаны кабул итү турында тамга

Дата: «__» ____________ 20__ ел.
Дәүләт техник күзәтчелек органы дәүләт инженер-инспекторы _____Имза _____

Техниканы карау турында мәгълүмат

Мөрәҗәгать итүче
тарафыннан тутырыла

Техниканы түбәндәге адрес буенча каравыгыз турында үтенәм
__________________________________________________________________________

Техника тапшыручы зат, ________________________________________

Дәүләт техник күзәтчелек органы дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан тутырыла
Техника түбәндәге адрес буенча
каралачак ________________________________________

Техниканы карау нәтиҗәләре

________________________________________
________________________________________
________________________________________
________________________________________

Карау датасы «__» ____________ 20__ ел.
Тикшерү үткәрү вакыты ________________________

Дәүләт техник күзәтчелек органы дәүләт инженер-инспекторы Имза ________
___________

Кабул ителгән карар турында мәгълүмат

<table>
<tr><td>ТЕРКӘРГӘ<br><br>Дата ____________</td><td>ИСӘПТӘН ТӨШЕРЕРГӘ<br><br>Дата ____________</td><td>ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТЕРГӘ<br><br>Дата ____________</td><td>ПСМ, ПСМ ДУБЛИКАТЫ БИРЕРГӘ<br>Дата ____________</td></tr>
<tr><td colspan="2">ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮНЕ ТУКТАТЫП ТОРЫРГА<br>____________ КАДӘР<br>Дата ______________</td><td colspan="2">ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮДӘН БАШ ТАРТЫРГА<br>Дата _______________</td></tr>
</table>

Түбәндәге документлар бирелде:

Техника паспорты (техника паспорты дубликаты) серия_________ N ________
Техниканы теркәү турында таныклык серия _________ N ________
«Тип 3» дәүләт теркәү билгесе серия _________ N ________
«Тип 4А» дәүләт теркәү билгесе серия _________ N ________
«Транзит» дәүләт теркәү билгесе серия _________ N ________
Номерлы агрегатка таныклык серия _________ N ________

Документларны бирде
----------------------

Дәүләт техник күзәтчелек органы дәүләт инженер-инспекторы _________________ Имза _________________

Документларны алды
------------------------

Фамилиясе, исеме, атасының

исеме (булган очракта)

Дата: «__» _________ 20__ ел.  Имза _____________

Үзйөрешле машиналарны һәм
башка төр техниканы теркәү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

форма Үзйөрешле машиналарны һәм
техниканың башка төрләрен дәүләт
теркәвенә алу кагыйдәләренә 2 нче
кушымтада китерелгән

Кая ___________________________________________________________

(үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торшышы һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органының тулы атамасы (алга таба – дәүләт техник күзәтчелек органы))

## Гариза

Кемнән __________________________________________________________,

(үзйөрешле машина һәм башка төр техника паспортында күрсәтелгән хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса))

| Тел. | ОГРИП | Салым түләүченең тәңгәллек номеры |
|---|---|---|
| | | |

сорыйм ___________________________________________________________

(үтенечнең нигезе һәм асылы бәян ителә, үзйөрешле машинаның һәм

_________________________________________________________________

һәм башка төр техниканың атамасы, маркасы, теркәү билгесе күрсәтелә)

Түбәндәге документларны тапшырам:
үзйөрешле машина һәм башка төр техника паспорты (алга таба – техника):
сериясе ______________________номеры _______________________________;
ОСАГО полисы номеры
сериясе ______________________________ ____________________

Техникага милек хокукын раслаучы документлар,

_________________________________________________________________

Башка документлар _______________________________________________

_________________________________________________________________

Дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр (түләү йөкләмәсе) түләү турында квитанция)

Документ N ________; дата «__» _____ 20__ ел; сумма: ________ сум.
Документ N ________; дата «__» _____ 20__ ел; сумма: ________ сум.
Документ N ________; дата «__» _____ 20__ ел; сумма: ________ сум.

Техника турында мәгълүматлар

Атамасы, маркасы ________________________________________
Завод номеры, идентификация номеры
(VIN яки PIN) __________________ Двигательнең завод номеры __________________
Тизлек күчерү коробкасының номеры ____________ Төп хәрәкәт мостының номеры ______
Төсе ____________ Җитештерү елы ____________ Утлы маякчык ____________

Техника хуҗасы турында мәгълүматлар

______________________________________________ Туу датасы __________________
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))
Шәхесне раслаучы документ,

(шәхесне раслаучы документ исеме, серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
Теркәлү адресы
________________________________________________________________
________________________________________________________________
Телефон ________________ Электрон почта адресы (булган очракта)_______________

Түбәндәгеләрне гамәлгә ашыруга риза булуымны раслыйм ________________________________________
________________________________________________________________
(Россия Федерациясе субъекты дәүләт техник күзәтчелек органының тулы атамасы)
минем персональ белешмәләрем белән (эшкә сәләтле булмаган затның – персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре белән (мөрәҗәгать итүче законлы вәкил булып торган очракта) түбәндәге гамәлләр башкарылуга: эшкәртүгә (персональ белешмәләрне җыюны, системага салуны, туплауны, саклауны, тәгаенләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), файдалануны, шәхси булуыннан туктатуны, таратуны (шул исәптән өченче затларга тапшыруны), файдалана алмаслык итүне, юкка чыгаруны да кертеп), шул исәптән автоматлаштырылган тәртиптә дә.
Әлеге килешү мәгълүматларны эшкәртүнең чик срокларын билгеләми. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны кире алу тәртибе миңа билгеле.
Персональ мәгълүматларны эшкәртү турында мәгълүмат тапшыру өчен персональ белешмәләр субъектының элемтә мәгълүматлары, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган башка очракларда да:
______________________________________________,
(почта адресы, телефон)
________________________________________________________________
(электрон почта адресы (булган очракта))

Имза ______ ____________________ Дата_____________

(тулы имза)

Милекче вәкиле турында мәгълүматлар

______________________________________________ Туу датасы __________

(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))

Шәхесне раслаучы документ, _______________________________

______________________________________________________________

(шәхесне раслаучы документ исеме, серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

Яши торган адресы _______________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

Ышаныч кәгазе _______________________________________________

Телефон _______________________Электрон почта адресы ________

Түбәндәгеләрне гамәлгә ашыруга риза булуымны раслыйм _______________________________________________

______________________________________________________________

(Россия Федерациясе субъекты дәүләт техник күзәтчелек органының тулы атамасы) минем персональ белешмәләрем белән (эшкә сәләтле булмаган затның – персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре белән (мөрәҗәгать итүче законлы вәкил булып торган очракта) түбәндәге гамәлләр башкарылуга: эшкәртүгә (персональ белешмәләрне җыюны, системага салуны, туплауны, саклауны, тәгаенләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), файдалануны, шәхси булуыннан туктатуны, таратуны (шул исәптән өченче затларга тапшыруны), файдалана алмаслык итүне, юкка чыгаруны да кертеп), шул исәптән автоматлаштырылган тәртиптә дә.

Әлеге килешү мәгълүматларны эшкәртүнең чик срокларын билгеләми. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны кире алу тәртибе миңа билгеле.

Персональ мәгълүматларны эшкәртү турында мәгълүмат тапшыру өчен персональ белешмәләләр субъектының элемтә мәгълүматлары, шулай ук законнарда каралган башка очракларда да: __________________________

______________________________________________,

(почта адресы, телефон)

______________________________________________________________

(электрон почта адресы)

Имза ________ ____________________ Дата__________

(тулы имза)

Гаризаны кабул итү турында тамга

Дата: «__» ___________ 20__ ел.

Дәүләт техник күзәтчелек органы дәүләт инженер-инспекторы ___________ Имза _______

Техниканы карау турында мәгълүмат

Мөрәҗәгать итүче
тарафыннан тутырыла
------------------------------
Техниканы түбәндәге адрес буенча каравыгыз
турында үтенәм ________________________________________

____________________________________________________________
Техника тапшыручы зат, ________________________________________

____________________________________________________________
Дәүләт техник күзәтчелек органы дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан тутырыла
Техника түбәндәге адрес буенча каралачак ________________________________________

____________________________________________________________

Техниканы карау нәтиҗәләре
____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________

Карау датасы «__» ____________ 20__ ел.
Тикшерү үткәрү вакыты _________________________

Дәүләт техник күзәтчелек органы дәүләт инженер-инспекторы Имза ___________ ________

Кабул ителгән карар турында мәгълүмат

| | | | |
|---|---|---|---|
| ТЕРКӘРГӘ<br><br>Дата ____________ | ИСӘПТӘН ТӨШЕРЕРГӘ<br><br>Дата ____________ | ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТЕРГӘ<br><br>Дата ____________ | ПСМ, ПСМ ДУБЛИКАТЫ БИРЕРГӘ<br>Дата ____________ |
| ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮНЕ ТУКТАТЫП ТОРЫРГА<br>____________ КАДӘР<br>Дата ______________ | | ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮДӘН БАШ ТАРТЫРГА<br>Дата _______________ | |

Түбәндәге документлар бирелде:

| | | |
|---|---|---|
| Техника паспорты (техника паспорты дубликаты) | сериясе | N |
| Техниканы теркәү турында таныклык | сериясе | N |
| «Тип 3» дәүләт теркәү билгесе | сериясе | N |
| «Тип 4А» дәүләт теркәү билгесе | сериясе | N |
| «Транзит» дәүләт теркәү билгесе | сериясе | N |
| Номерлы агрегатка таныклык | сериясе | N |

Документларны бирде
-----------------------

Дәүләт техник күзәтчелек органы
дәүләт инженер-инспекторы Имза ___________

Документларны алды

-------------------------

Фамилиясе, исеме, атасының
исеме (булган очракта)

Дата: «__» ____________ 20__ ел. Имза ____________

Үзйөрешле машиналарны һәм
башка төр техниканы теркәү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

форма Үзйөрешле машиналарны һәм техниканың
башка төрләрен дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләренә
3 нче кушымтада китерелгән

## ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАНЫ ҺӘМ ТЕХНИКАНЫҢ БАШКА ТӨРЛӘРЕН ДӘҮЛӘТ ТЕРКӘВЕНӘ АЛУ ТУРЫНДА ТАНЫКЛЫК

Серия ____________ N _______________

(Нәрсәгә)________________________________________________________________________
(үзйөрешле машинаның һәм башка төр техниканың атамасы (алга таба – техника)

Дәүләт теркәвенә алу билгесе, тибы__________, коды ________,
сериясе ___________, № ________________________________________________
Маркасы ________________________________Чыгарылу елы___________________
Техниканың (рамның) завод (идентификация) № ____________
Двигатель № _______________________________________
Тизлек күчерү тартмасы № ______Төп хәрәкәт мосты (мостлары) № ______
Төсе ________________________________________________________________
Хуҗасы ___________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) яки
_____________________________________________________________________
оешма – техника хуҗасы атамасы)
_____________________________________________________________________
(адрес)
Таныклык бирү нигезе _________________________
_____________________________________________________________________

Мөһер
урыны ______________________________________________________________
(үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың, аттракционнарның

____________________________________________________________
техник торышы һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органының (алга таба – дәүләт техник күзәтчелек органы) баш дәүләт инженер-инспекторы)

«__» ____________ 20__ ел.

*(2 нче бит)*

Техниканың төп компонентларын алыштыру турында мәгълүмат

| Алмаштыру датасы | Техниканың төп компоненты атамасы һәм номеры | Дәүләт техник күзәтчелек органы дәүләт инженер-инспекторы имзасы һәм мөһере (булган очракта) |
|---|---|---|
| | | |

Искәрмә __________________________________________________

Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

ТР Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе бүлеге җитәкчесе

____________________________________________
бүлекнең территориаль атамасы, район, шәһәр күрсәтелә
баш дәүләт инженер-инспекторы
____________________________________________
инженер-инспекторның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)
____________________________________________
мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)
паспорты
____________________________________
сериясе, номеры, кем тарафыннан бирелгән, бирелгән датасы
____________________________________________
яши торган адресы: ___________________________
____________________________________________

## Техник хатаны төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен биргәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.
Кая_____________________________________________________________________
(бирелгән документ)
күрсәтелгән
_______________________________________________________________________.

Дөрес мәгълүмат:
_____________________________________________________________________________.

Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.

Документның әзер булуы турында миңа түбәндәгечә хәбәр итүегез турында үтенәм
_____________________________________________________________________________.
(хәбәр итү ысулы)

________________________________ (____________________________________________)
(дата) (имза) (тулы имза)

Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Идарә җитәкчесе | 221-77-85 | gostehnadzorrt@mail.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе җитәкчесе | 264-77-15 | prav@tatar.ru |